ISSN 0136-7110

Чаян



9

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ СЕНТЯБРЬ * 2020 * КАЗАН

Михаил ЛАРИЧЕВ



Алмаз ХӘМЗИН

КАПКЫН КУЯ...

Алдамаган безне илбаш –
Пенсияне арттырган.
Ике йөз житмеш дигәнен,
60 сумга калдырган.

Элек халыкны куркыткан
Җиде башлы аждаһа.
Хәзер безнең башны ашый
Иң комсыз дус – ЖеКеХа.

Җор сандугач калган, диләр,
Тирә-якта берүзе.
Шуны чакрып сайратырга
Үтми халыкның сүзе.

Нигә яна бу урманнар,
Нигә кибә бу сулар?..
Тайга беткәч ни суларбыз?..
Һава сатырлар байлар.

Нишләп кан басымы арта,
Нишләп болгана күңел?
Югыйсә сайлаулар да бит
Инде ел буе түгел.

Ризасызлык – шаулый халык,
Ишетелми шаулавы.
Синоптиклар әйткән күк –
Яңгыр яву, яумавы...

Байлар юк бездә, диләр дә...
Безнең байлар чит илдә.
Ниләр, кемнәр генә юктыр,
Без ашаткан бу җирдә?..

Аңламыймын хөкүмәтне,
Нигә кылана шулай?..
Үз-үзенә капкын куя –
Үзе эләгер бугай...

ГАФУ ИТМӘСЛЕК САТАШУ

Тукай булмаган, дип әйткән
Өфедәге бер галим.
Галим түгелдер ул адәм,
Чынлап, билләһигазим.





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Безнең белгечләрнең дөньяда беренче булып коронавирустан вакцина уйлап чыгарып теркәве булды, бөтен чит ил медицинасы эченә таяк тыккан кырмыска оясына охшап калды. Шунда ук тискәре мәгълүмат дулкыны күтәрелде – имеш, яңа препарат шикле, файдасыз һәм ашык-пошык эшләнгән... Ә бу шау-шу артында кемнәр торганын беләбез бит. Шуның аркасында аларның миллиардлаган доллар югалтуы мөмкин...

Р. ДӘҮЛӘТШИН

АЛАБУГА

Укучының хатын укыгач, Шомбай агабыз истәлекләр диңгезенә чумды.

– Исемдә, 1961 елның 12 апрель көнне, – диде аксакал, **– көнбатыш радиоларыннан хәбәр яңгырады: имештер, дөньяның бөтен галимнәре совет космик корабльләренең ышанычлы булуында шикләнәләр, ә безнең космонавтлар исә «Хрущёвның тәҗрибә тычканнары» икән. Алар үзләре күптәннән космоска кеше җибәргән булырлар иде, ләкин башта Советлар иленең кайда ялгышканын күрергә кирәк... Бу сезгә берни дә хәтерләтмиме?**

Александр ШУЛЬПИНОВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Халык бәхете өчен көрәшүчеләр бәхетле кешеләрне өнәми.

Хәтта тарих чүплегенә эләгер өчен дә тарихи шәхес булырга кирәк.

Тарих сабаклары тарих дәресләрендә *сөйләү өчен генә кирәк.*

Даһилык талантлар белән көрәшкәндә генә күренә.

Даһи фикерләр, гадәттә, халык мәкальләрен кабатлый.

Нәчәлник, гадәттә, өскә таба егыла.

Иң лаеклыларны – лаеклы ялга!

Аз вәгъдә итүгә караганда, артыгын вәгъдә итү яхшырак. Халык саранннарны яратмый.

Халыкка, нишләптер, акыллы баш түгел, ә көчле кул кирәк.

(акыл сандыгын актарганда язып алынды)



Игорь КИЙКО





Шәһәр яны урманнарында бүген адашу мөмкин түгел – йә тегендә, йә монда җәелеп яткан чүп кисәкләре барыбер олы юлга алып чыга.

Казан тирәсендәге урманлыкларда булган һәр кеше аларның күптәннән зур чүплеккә әйләнеп беткәнен белә. "Табигать сөючеләр"нең шашлык ясап, кәеф-сафа корып утырган урыннарына адым саен килеп төртеләсең. Бөтен җирдә гадәттәге нәрсә – пыяла шешәләр, пластик савыт-пакетлар, тәмәке төпчекләре, шакшы кәгазь кисәкләре аунап ята...

"Күп сүз – чүп сүз" дигән гыйбарәне истә тотып, үзебез белән чүп капчыклары һәм перчаткалар алып, кояшлы августның бер көнендә Боровое Матюшино ягына юл тотабыз.

Менә, шәһәрдән чыгып, Лаеш юлы буйлап Усад авылы яныннан узабыз. Берничә чакрымнан соң урман читендә тукталабыз. Урман эченә кереп берничә адым үтүгә ял итүчеләрдән калган ертык кәгазь кисәкләре, сок пакетлары һәм дистә еллар буе таркалмыйча яткан пластикка юлыгабыз. Ирексездән: "Моны пакетка җыеп, юлда контейнерга ташлап китү авыр булды микәнни", – дип уйлап куясың. Кулга перчаткалар киеп, чүпне капчыкларыбызга җыя башлыйбыз...

Юлыбызны дәвам итәбез. Комлы Кавәл борылмасын узып китеп, юл янындагы наратлыкка юл тотабыз. Бормалы сукмак безне яшел аланга алып чыга. Мондагы чүплек безне инде гаҗәпләндерми дә. Яңадан капчыклар чыга. Тулы капчык белән машина янына кайтабыз. Юлыбызның дәвамы мәһабәт наратлар арасыннан уза. Зелёный борга таба борылабыз. Юл буенда шул ук таныш күренеш. Чүп, чүп, чүп...

Ике сәгатьлек сәяхәтнең нәтиҗәсе булган чүп тулы ике капчыкны ишегалдындагы контейнерга ташлап калдырдык.

Ләкин бу безнең хикәятнең башы гына иде. Шәһәр яны урманнарында ял итүчеләрдән калган чүп-чардан күпкә җитдирәк нәрсәләргә юлыгырга була. Бу – мәркәзебезнең төрле почмакларыннан килгән тәзелеш-ремонт чүбе таулары. Аларны очраткан саен, гаҗәпләнеп куясың: нигә ватык кирпеч һәм пыяла кисәкләре, шифер кыйпылчыклары төягән йөк машиналары тиешле урынга барып җитми соң? Нигә алар урман эчендә генә "бушаналар"?

Сәер тоелса да, моның сәбәбе – ил буенча киң адымнар белән атлаучы, аны чистартырга тиешле "чүп реформасы" булып чыга. "Каты коммуналь калдыклар" турында яңа кагыйдәләр кертелү белән, аны чыгару күпкә кыйммәтләнде. Һәм чүпне утилизацияләү өчен региональ оператор – лицензияле оешма белән килешенү төзергә кирәк. Ә ул һәр кубометр өчен 790 сум сорый, өстәвенә, түләгәндә кубометрлар күләмен дә арттырып җибәргәли...

– Элек мондый катлаулыклар юк иде, – диләр чүп мәсьәләсен төптән белгән әңгәмәдәшләр, – машинаны читтән алырга була иде, ә полигондагы сакчы арзан гына түләү өчен чүпне кабул итә иде. Хәзер исә андыйларны борып җибәрәләр, өстәвенә, машина йөртүчеләрне чүп белән законсыз эш иткән өчен штрафка тарталар... Һәм алар урман ягына борылалар...

Ә безнең яшел байлыгыбызны сакларга тиешле урманчылар кайда соң? Кызганыч, берёзлексез артып торучы чүп таулары белән көрәшергә кешеләре, акчалары, көчләре дә юк. Һәм аларның үз мәшәкатьләре дә муеннан...




Игорь КИЙКО


Бүгенге көндә табигать анабызны сакларга өндәүче плакатлар, тәрбияви әңгәмәләр үз максатына ирешми. Штрафлар да һәрвакыт ярдәм итми – тәртип бозучыны бит аны тотарга, гаебен исбатларга кирәк... Һәр агач төбенә сакчы да куеп булмый бит...

Урман саклаучылар кул кушырып утырмый, әлбәттә. Көрәш булгач, фронттагыча булырга тиеш – шуңа күрә урманга алып керүче кечкенә юлларга аркылы бүрәнәләр куела һәм канаулар казыла. Бу чаралар мәсьәләне тулысынча хәл итмәсә дә, Казан арты урманнарының шигъри гүзәллеген аз булса да саклап калыр дип ышанасы килә...

Рамил ИСЛАМОВ

Валентин **ДУБИНИН**





Сергей **АНДРИАНОВ**



• • •

– Доктор мине ике атнада аягыңа бастырам дигән иде. Һәм чыннан да: дәваланып, аның өчен акча кирәк булгач, машина сату мәшәкате белән чабарга туры килде...

• • •

"Кулың белән язганны – балта белән чабып бетерә алмыйсың" дигән мәкаль бераз искерде. Ә хәзер "Клавиатурада язганны – арматура белән дә каерып чыгара алмыйсың", дигәне урынлырак.

• • •

Урыс токымнары чит илдә яши.

Революционерларның токымнары чит илдә яши.

Совет генсекларының токымнары чит илдә яши.

Күренекле оппозиционерларның токымнары чит илдә яши.

Хәзерге түрәләрнең гаиләләре чит илдә яши.

Һәм үзара бөтенесе дә Россияне ничек итеп үзгәртеп кору турында бәхәсләшәләр.

• • •

Дөрес итеп сөйләшкәндә "ярлы-ябагай"ны "финанс мөмкинчелекләре чикле булган кешеләр" дип әйтергә кирәк.

• • •

Адвокат клиентына киңәш бирә:

– Сезнең хәлдә иң яхшысы – хатыныгыз янына кире кайту.

– Бик кызык! Ә сезнеңчә минем өчен иң начары нәрсә була инде?

• • •

Берәү күршесенең перфораторыннан котылырга уйлаган. Этаж арасындагы стенага: "Җәүдәт, мин балага уздым", – дип язган. Хәзер инде күршесе бораламый, хатыны икенче көн акыра, ә перфоратор белән чагыштырганда тавышы чүп кенә.

• • •

Соңгы вакытта дөньякүләм мәсьәләләр шулхәтле катлауланды, бу хәлне чишәргә хәтта таксистлар да алынмый.

• • •

– Самокатта йөрүче яшьләр күбәйде.

– Әйе, бер аягы озынрак һәм көчлерәк буын үсеп килә.

• • •

– Официант, сырага чебен төшкән бит!!

– Вакланып утырмагыз инде! Кеп-кечкенә чебен сырагызны күпме эчә ала инде?

Абау!

АЛГЫ САФЛАРДА

Татарстан коррупция белән бәйле җинаятьләр саны буенча беренчеләр сафына чыккан. Генераль прокуратура мәгълүматлары буенча, республикада 2020 елның беренче яртысында ришвәтчелек очраклары саны 707 гә кадәр үскән. Ләкин тынычланырга иртә: республикадан алда әле 1400 ришвәтче тотылган Мәскәү һәм 708 коррупционерлы Краснодар крае бара. Тик моның икенче ягы да бар: "алдынгы" өлкәләрдә бу санның җинаятьләрне ачу эше шәбрәк куелуы белән бәйле булуы мөмкин....

ЯЛГАН АГАРТУ

Тукай районының Башкарма комитеты җитәкчесе Ленар Авзаловны ялган агач агартуда гаеплиләр. Тикшерү органнары фикеренчә, чиновник 16 авыл җирлеге башлыгын агач кисү һәм агарту эшләрен кабул итү турындагы актларга имза куярга мәҗбүр иткән. Чынлыкта исә бу эшләр башкарылмаган, ә моның өчен каралган 1,6 миллион сум башлыкның якын танышы, эшмәкәр Мөнәсиф Ханов кесәсенә барып кергән. Тикшерүчеләр Авзаловны бизнесменга бюджет акчасын үзенә затлы мунча салдырган өчен күчергән дип уйлыйлар.

ҖЕНСИ ТИГЕЗСЕЗЛЕК

Казандагы Үзәк универмаг янында хатын-кызлар өчен генә ясалган парковка барлыкка килгән. Аны алсу төскә буяганнар, ә машина урыннарын гадәттәге 2,5 метрдан 4,4 метрга кадәр арттырганнар. Ләкин бу тәҗрибәнең тормышы озакка сузылмаган. Республика прокуратурасы, бу "алсу парковка"да җенси билге буенча дискриминация күреп, аны юкка чыгаруны таләп иткән.

РӘШӘТКӘ КИРТӘ ТҮГЕЛ

63 яшьлек бер Казан пенсионеркасы мошенничество өчен Удмуртиядәге төзәтү колониясенә барып эләккән. Тик күптән түгел аңа карата полициягә тагын гаризалар килә башлаган. Зыян күрүчеләр белдерүенчә, үткен ханым, дәүләт органнарында булган элемтәләре белән кызыктырып, уңай шартлар белән фатир сатып алуда ярдәм вәгъдә иткән. Пенсионер хатын инде 4 миллион сум аванс алырга өлгергән. "Төрмә эшмәкәре"нә карата тагын бер җинаять эше кузгатылган.

Александр БРЮХАНОВ

Иң мөһиме

Иң мөһиме – кәефең шәп булу.

Иртән күземне тырнап ачам, сул аякка басам дигәндә, ул бөгелеп китә һәм чырай белән тумбочкага чәчрәп төшәм. Ләкин шунда ук уң аякка басам, һәм кәеф менә дигән.

Җылытырга куйган ботка янарга өлгергән, аның каравы, аннан соң фатирымны җиллэтәм. Саф һава кәефне күтәреп җибәрә...

Ишегалдында урам себерүчене очратып, аның турында бөтен уйлаганымны әйтеп бирәм, ә ул – минем турында... Кәеф тагын да күтәрелеп китә – ул минем турында уйлый икән бит әле...

Эшкә чабам, сыеп керә алмыйча өч автобус уздырып җибәрәм, аның каравы, рәхәтләнеп җәяү китәм, барышлый йөгерүгә күчеп, теге автобусларны узып китәм... Кан уйный, шундый рәхәт, кәеф тә шәп...

Эшкә соңарып киләм, әлбәттә, аның каравы, начальниктән соңгы берничә ел буе эчендә тотып йөргән сүзләрен ишетәм. Нәкъ минем аңа әйтергә теләгән сүзләр икән. Көне буе күтәренке күңел белән йөрим...

Эштән кайтышлый кибеткә керәм, чиратта торган арада продуктлар турында шулкадәр күп нәрсә ишетергә өлгерәм ки, берни дә алмаган килеш кайтып китәм. Шатлыгым эчкә сыймый – күпме акча янга калды бит...

Өйдә хатын, гадәттәгечә, эшләнеп бетмәгән ремонт, искергән өстәлурындыклар, тамып торучы кран турында сүз башлый. Бер яктан, күңелсез, ә икенче яктан – әгәр сүгенә икән, димәк, минем хатыным бар, ул миңа битараф түгел, һәм өйдә барысы да тәртиптә дияргә була. Кәефләр шәп.

Телевизордан яңалыклар карыйм – кайдадыр янгыннар, кемнедер су баскан, ә минем диванда йомшак һәм рәхәт. Кәеф тагын да күтәрелә...

Сак кына, әйбәт кәефне бозмаска тырышып, йокларга ятам: аны бит иртәнгә кадәр саклап калырга кирәк...





БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Татарстандагы этләр бәхетле, чөнки аларның туган теле юк. Шовинизм сәясәте аларның ирен тамчы да кыерсытмый.

Алмаз Хәмзин: Ялгышасың, Рашат дус, аларның туган теле бар – "Вау!" (Татарча шулай). Бер сүз өчен сине кем кыерсытып торсын?.. Шуңа күрә алар ирекле дә. Бәйдәгесе бигрәк татар шикелле...

Р. Н.: TV каналларын да цифрлаштырып бетерделәр. И Ходаем, кешеләрне цифрлаштыра күрмәсеннәр!

А. Х.: Цифрлаштыру пүчтәк ул, менә маскаладылар, изоляцияләделәр, вирусладылар, обнулили... Юк без хәзер, юк...

Р. Н.: "Зөләйха" романы авторы Гүзәл Яхина: "Мин әбиемнең күргән-сөйләгәннәрен яздым", – дип aклана. Димәк, әсәрдә тормышны, "фотографияләү" ысулы өстенлек алган. Юкса биредә милләтебезнең югары рухын, әхлагын сәнгати күрсәтү үзмаксат булырга тиеш иде.

А. Х.: Идеологиясе булмаган илдә мондый максатлар куелмый. Ә менә әсәр эчтәлегендә хакимнәр үзләренә яраклаштыру алымын оста кулланалар. Моңа романда җае чыгып торган сюжетлар байтак.

Р. Н.: Тугрылыкта этләр генә адәм белән ярыша ала.

А. Х.: Бу мәсьәләдә өстенлек этләрдә. Чөнки эт чыннан да тугрылык белән эш йөртә, кеше – үзенә файда белән.

Р. Н.: Илдар Юзиев әйтер иде: "Исәнлек пүчтәк ул, сәламәтлек кирәк!" – дип.

А. Х.: ...һәм шулай да!..

Р. Н.: Космос формуласын, образлы итеп, берничә сүз белән әйтеп була: Кояш – галәм чибәренең нурлы йөзе, йолдызлар – шул илаһи кыз йөзендәге сипкелләр, Ай – җиһанның сыңар алкасы...

А. Х.: Ә Рашат?.. Коньяк йолдызлыгының...

Р. Н.: Үзеңне тәнкыйтьләүгә караганда, кешене сүгү ансатрак.

А. Х.: Безнең җәмгыятьтә хәзер тәнкыйть тә, сүгү дә юк, бары тик сүгенү генә бар.

Р. Н.: Коронавирус зәхмәте хакимиятнең бугазына баскач, Рәсәйдә "милли өстенлек" чире кимеп куйды. Озакка микән?

А. Х.: Ул тынып тормады. Һәм кабат, коронавирусның бер төре булып, калкып чыгачак. Хәзер бит барлык чирләрне шул зәхмәткә туплыйлар.

Р. Н.: Әгәр дә Рәсәйнең сәяси "ниша"сы бушап кала икән, ул урынны яһүд яки татар биләп алачак.

А. Х.: Әйдә, без бу фикереңне иҗатчылар буларак, үзебезгә сылтыйк та, акыллы төс ясап, эндәшмик. Без бит тәхеттә ничәмә-ничә мәртәбә утырып, аннан коры калган кавем.

Синең соңгы бер шигыреңне мисал итеп китерү дә бик җитә:

СУВЕРЕНИТЕТ

Такташ сыман: "Аһ, анасын"... – диеп,
Кирәк микән аллә сүгенергә?
Безнең ять-яшь суверенитетыбыз
Калды бары... кәгазь "сувенир"га!


Александр КОСМЫЛИН



Вячеслав ШИЛОВ



Константин ЧАХИРОВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Бер кызның Инстаграмында тун кигән бик күп фоторәсемнәр күрсәтелгән иде. Бөтенесе аны бик бай дип уйлаганнар, ә ул театрда кием элә торган җирдә эшләгән булып чыкты.

• • •

Хатын-кызда тыныч кына аңлап булмаслык ике фикер яши: "кызларның хәтере кыска" һәм "мин сине, кабахәт, беркайчан да онытмам".

• • •

Әгәр инглиз икән – ул тел йөртүче икән, инглиз телен мәктәптә укытучы – ул инде йөктыручымы?

• • •

Бер банкир – икенчесенә:

– Сезнең кассир акчагызны һәм кызыгызны алып качкан, диләр. Дөресме?

– Кызганыч, шулай шул. Ләкин ул миңа барын да кайтарачакмын дигән язу калдырган. Кызны кайтарды инде...

• • •

Ире – хатынына:

– Бүген автобустагы этеш-төртешне күрсәң син! Хәтта бер корсаклы хатын бала тапты.

– Исең киткән икән! Шул этеш-төртеш аркасында узган айда мин корсакка да уздым әле!

• • •

Психиатр янында.

– Сез үзегезнең эт икәнегезне беренче тапкыр кайчан сиздегез?

– Көчек чагымда..

• • •

"Мәрхәмәтле кулларга көчек һәм песи бирәм" дигән белдерүләр күп хәзер. Менә шунда, ичмасам, берсе, "Мәрхәмәтле кулларга симез сарык бирәм" дигәнен бирсен иде!

• • •

Шулай да без бик алга атладык! Әгәр 30 ел элек кайнар суны туктату турындагы белдерүләрне кулдан язып, ишек төбендәге тактага элсәләр, хәзер принтерда чыгарып, кубарып булмастай итеп ябыштыралар.





Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Наил КАСЫЙМ

"Тарихның җиз иләгендә иләнеп, язган бер генә җөмләң исән калса да, син – бәхетле иҗатчы".

Сибгат ХӘКИМ

ӘРСЕЗЛӘРГӘ...

Чират көтми узган әрсезләргә
Карыйсың да – хәйран каласың.
Баш өстеннән йөри алар хәзер,
Ай-һай, азды адәм баласы!

Әрсезлектән туйган инде дөнья,
Язасы да килми бу хакта...
Рухи чүплек булып, ул төпләнеп,
Чәчәк ата бигрәк иҗатта.

Дан артыннан куа тавышсызлар:
"Мин – җырчы!" – дип чәчрәп чыгалар.
Исемнәре: атказанган, халык...
Тыңлый алсаң, тыңла... Күп алар!

Китап язып, ярышалар күпләр:
"Синең ничә? Минем йөз икән..."
Бу тормышта кайчак бер китап та
Дәрдмәнд булыр өчен бик җиткән!

Әнә, берәү кабарынып сөйли:
"Халык язучысы абзагыз!.."
Халык аның язган бер җөмләсен
Белә микән – сорап карагыз?!

Кем властька якын – дуслары күп,
Ә дусларның була туганы.
Нәрсә тора шул дус-туганнарга
Халык исемнәре "урлавы"!..
(Бардыр тагын башка юллары...)

Иҗатка бит тарих бәһа куя,
Бик тиз узар гомер еллары.
Мин аларны җәлләп уйлап куйдым:
"Кемгә кирәк исем коллары?!"

ҮЗЕН ЗУРГА КУЮЧЫГА

Диңгез – күлдән тирәнрәк,
Томан – таудан түбәнрәк,
Чәчәк түгел – тигәнәк...

Күпме генә сикерсәң дә,
Буең кала тәбәнәк!..

БЕР КИТАПКА РЕЦЕНЗИЯ

Күләгә бар – үзе юк,
Тавышы бар – сүзе юк...

• • •

Фил артыннан бер эт чаба,
Өрә ярсып, ә ул бара...
Филгә аны кем дә өрә,
Үз хуҗаңа өреп кара.

Дамир МОРТАЗИН

Йөрәк яна

"Кара инде, ә! Урман белән нишлиләр! Менә таза-сау наратны аударганнар – череп ята. Ул кемгә комачаулаган? Шунысына ис китә – берәүнең дә эче пошмый. Түрәләр үз кесәләрен кайгырта, ә халыкка коры-сары... Бу хәлгә, үтереп, йөрәк сыкрый...

Кайдадыр якында гына янгын котырына. Төтен астыннан *кечкә кояш күренгәли. Бөтен ил буйлап* янгыннар... һәм шуны һич баса алмыйлар... Йөрәк тә яна, янган урман көлләрен күреп...

Әнә аюлар да чыккан өннәреннән төтенгә тончыгып. Балалары кызганыч – аларга бит әле үсәргә дә үсәргә генә. Кызыл китапка кертергә калмаса ярар иде инде, мескенкәйләрне. Пожар үтермәсә, нинди дә булса берәр губернатор башларына җитәр... Ерткыч бәндә! Менә шуны күрә торып йөрәгең ничек канга батмасын?

Ә нәрсә эшләргә соң? Кем гаепле? Бу хәлләр булмасын өчен кем җавап бирергә тиеш? Без бит үзебез моңа каршы бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Проект тәкъдим итсәк кенә һәм грант отсак, ләкин бу афәттән котылу җаен тапканнарга кем акча бирер... Тагын йөрәктән кан саркый..."

"Яшеллек өчен" дип аталган иҗтимагый экология оешмасының җитәкчесе Урманов авыр сулап куйды да, Шишкинның стенада эленеп торучы "Иртәнге нарат урманында" дигән картинадан моңсу карашын алып, кунакханә караватында тирән йокыга талды.





Ринат АБЗАЛОВ

МӘХРҮМ БАЛАЛАР

Шундый шәп бер затлы сарайда –
Кемнәр икән чыр-чу килешә?
Балаларга бик бай абзыйлар
Өч тиенлек ярдәм өләшә.
Ә үз балалары, мескеннәр,
Баштанаяк көмеш-алтында,
Бу ярдәмнән мәхрүм калалар –
Яши алар чөнки Лондонда...

КЕРЕП КИТТЕ...

Инде соңгы өмет чаткылары
Сүнеп барган чакта күңлемдә,
Күрдем кинәт уктай төз сыныңны –
Нур балкыды соры күгемдә!

Сөю сирпеп, нәфис бармакларым
Үрелделәр сихри шәүләгә...
...Җылы майга кашык баттымыни –
Кереп китте
җебем
энәгә...



АДАШКАН ФИКЕРЛӘР

• Бүгенге укучыларны бөтенләй тәрбиясез дип булмый: алар укытучыларга «сез» дип эндәшәләр һәм аларның исемнәрен онытмыйлар.

• Укытучыларның урта хезмәт хакы Лох-Несс җанвары кебек – күпләр аның турында белә, кайберәүләр аның булуына ышана, ләкин чынбарлыкта аны беркем дә күрмәгән.

• «БДИ корбаннары» дигән сүз аеруча ләззәт белән МММ корбаннары авызыннан чыга.

• Түләүсез бүлектә укыр өчен, еш кына акча җитми башлый.

Николай **ФИЛИМОНОВ**

Николай **ВОРОНЦОВ**





Игорь **КИЙКО**





МИРЗАҺИТ ТОРМЫШЫННАН

ЧИЯ

Мирзһитның йорты янында зур чия агачы үсә. Бер елны ул бик куе, яфраклары да күренмәслек итеп чәчәк ата. Чия бар кешене сокландырып, актан киенгән яшь кәләш кебек тора. Шул вакытта күршесе Вәли Мирзаһитның балтачүкеч тотып, агач янында маташканын күреп ала.

– Нишлисең, күрше, койма төзисеңме әллә? – дип сорый ул.

– Күрәсең бит, ничек чәчәк ата, малай-шалай чия урларга йөриячәк бит. Чара күреп куярга кирәк.

– Ә нигә шулхәтле ком ташыдың?

– Барыбер йөриячәкләр бит. Коймадан егылган чакта йомшаграк булсын диюем, – дип җавап биргән Мирзаһит күршесенә.

НИХӘТЛЕ МӘШӘКАТЬ...

Авылда Сәгыйрь исемле кеше була. Өй салырга теләми, хатыны белән кәкрәеп беткән җимерек йортта яши бу. Авылдашлары әллә ничекләр үгетләп карыйлар: төзегәндә ярдәм тәкъдим итәләр, хәтта уңайлы урынын да табып бирәләр.

– Үгетләмәгез, кирәк түгел миңа өй. – Ә мин шәһәргә китәргә уйласам? Нихәтле мәшәкать бит...

Аның хатынын җәллиләр, ә Сәгыйрь үзенекендә тора:

– Төзеп куярмын менә, ә ул янып китсә... Нихәтле мәшәкать...

Авылдашлары аның белән берни дә эшли алмый.

Беркөнне моның янына Мирзаһит килеп, янәшәсенә утыра.

– Тыңла әле, Сәгыйрь, менә төнлә син йоклаган чакта бу абзарың җимерелеп төште ди. Без бит сине зиратта җирләмәячәкбез. Мәңгегә шушында ятып каласың...

– Нигә алай? – дип гаҗәпләнә Сәгыйрь, авызын ачып.

– Уйлап кара – сине башта казып чыгарырга, аннан соң күмәргә кирәк булачак. Нихәтле мәшәкать бит бу...

Сәгыйрь тирән уйга бата. Ә берничә атнадан аның ягыннан балта тавышын ишетәләр – ул өй сала башлый. Мәшәкатьләр аны инде куркытмый....

КУНАКЧЫЛ КИЛЕН

Беркөнне Мирзаһит эшләре буенча күрше авылга барып чыга. Берьюлы улының гаиләсе белән күрешеп чыкмакчы була. Баскычта ук аны килене каршы ала::

– Без бүген иданне буяган идек, керергә ярамый...

«Ярый инде, була торган хәл», – дип уйлый Мирзаһит, һәм дуслары янына китә.

Икенче килүендә дә аны ишегалдында килене каршы ала:

– Бүген дихлофос белән чебен агулаган идек, бөтен өйне бастылар! Үзебез дә кермибез...

Бу юлы да Мирзаһит дуслары янына китә.

Өченче тапкыр барганда ул үзе белән бик зур ике кавын алып илә. Килене аны ерактан ук күреп алып, кул болгый, үзе янына чакыра..

– Беләм, беләм, – дип кычкыра аңа Мирзаһит. – Бүген сез таракан агулыйсыз икән дип ишеттем!

Һәм турыдан-туры дуслары ягына юл тота.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ

Максим СМАГИН









ЮМАРТ ПОСОБИЕ

Башкортстан түрәләре республикада кадрларның нигә җитмәвен аңлатканнар. Нефтекамск шәһәренең эш белән тәэмин итү үзәгенең директор урынбасары Ирина Семенихина әйтүенчә, сәбәп эшсезлек өчен түләнә торган пособиенең бик "юмарт" булуында. Аның исәпләвенчә, регион буенча пособие 5175 сум, ә эшсезнең өч баласы булса, гомуми түләү якынча 15 мең сум чыга. Түрә фикеренчә, бу хәтле акча кешегә эшләмәскә һәм рәхәт тормышта яшәргә мөмкинлек бирә.

СУЛ КУЛ БЕЛӘН

Орёл шәһәренең депутаты Михаил Вдовин шәһәр үзәгендә җәйгән юлны үз куллары белән тикшереп караган. Җирле халык асфальтны дөрес итеп салмаганлыгына зарланган. Депутат үзәккә килгән һәм сул кулы белән Роза Люксембург урамындагы яңа салынган асфальттан зур бер кисәк каерып алган. Аның әйтүенчә, кызып киткән булса һәм вакытында туктап калмаган булса, салынган юлның зур өлешен куллары белән сүтә алган булыр иде.

МАХСУС БҮЛМӘ

Иркутск өлкәсендәге Манзурка поселогының мәктәбендә гадәти булмаган бәдрәф бар. Мәктәптәге ремонттан соң бүлмәдә унитазлар урнаштырганнар. Аларны бер-берсенә терәп куйганнар һәм анда йомышыңны үтәп булмый. Балаларны урамдагы бәдрәфкә йөрергә мәҗбүр иткәннәр. Түрәләрнең бу күренешкә гадәттәгечә, үз фикерләре бар – районның мәгариф бүлеге белдерүенчә, бу бәдрәф түгел, ә унитазлар саклый торган махсус бүлмә икән.

КИРӘК БУЛМАГАН УҢАЙЛЫКЛАР

Николаевск-на Амуре шәһәрендә Луначарский урамындагы чокырны ватык кирпеч белән тутырып куйган ир кешене эзлиләр. Җирле идарә фикеренчә, тырыш гражданин юлда чүплек ясаган, ә моның өчен 4 мең сум штраф каралган. Түрәләр әйтүенчә, үз белдеге белән юл рәтләүгә караганда, чокыр шул килеш торса куркынычсызрак икән.



Быел Казан сәнгать училищесы оештырылуга 125 ел тула. Аның данлы тарихы 1895 елның 9 сентябрендә башлана. Нәкъ шул көнне Император художество академиясе Президенты, бөек кнЯзь Владимир Александровичтан аны ачуга рөхсәт алына. Ә аны булдыруның башында Художество академиясен тәмамлаган Н. Н. Белькович, Х. Н. Скорняков, Г. А. Медведев, Ю. И. Тиссен һәм А. И. Денисов тора. Бу Художество академиясенә буйсынган беренче урта махсус сәнгать уку йорты була. Аны тәмамлаган аеруча сәләтле укучылар укуларын Санкт-Петербургта дәвам итә торган була.

Революциядән соң училищедагы иҗади тормыш яңа төсмерләр ала. Модерн, авангард, экспрессионизм һәм абстракционизм кебек төрле юнәлештәге сәнгать төркемнәре барлыкка килә. Тик егерменче еллар ахырында аларның күп кенә вәкилләре укыту эшен ташларга, хәтта чит илгә китәргә мәҗбүр була. Алар арасында иң күренеклесе Николай Фешин була. Училище бүген аның исемен йөртә.

Һәм шул вакыттан Казан сәнгать училищесында һәм бөтен илдә совет чынбарлыгын һәм аның казанышларын данлаучы социалистик реализм төп юнәлешкә әверелә. Әйтергә кирәк, катгый эстетик һәм идеологик кысаларга карамастан, Казан рәссамнары үз эшләрен оста һәм кеше күңеленә үтәрлек итеп башкаралар. Аларның эшләре Рәсәйдә генә түгел, ә башка илләрдә дә танылa.


Ул елларда сәнгать мәктәбен меңләгән рәссам, скульптор, график һәм архитекторлар тәмамлый. Аларның күпләре Татарстан һәм Россиянең сәнгать тарихында урын ала. Сәнгать белән таныш кешеләргә Г. Медведев, Н. Фешин, Д. Бурлюк, П. Беньков, А. Родченко, Б. Урманче, П. Дульский, Н. Соколов (Кукрыниксы төркеменнән), Х. Якупов, Л. Фәттахов, И. Хәлилуллов, И. Ханов, К. Васильев һәм башкаларның исемнәре яхшы таныш.

Училищенең «җитди» академик юнәлештәге белгечләр әзерләвенә карамастан, алар арасыннан күпләр шаян карикатура жанрында да эз калдырды. Төрле еллардагы «Чаян» битләрен актарып карасаң, анда күп кенә Казан сәнгать училищесын тәмамлаган рәссамнарның исемен очратырга була. Бүгенге вернисажыбыз – бу бай тарихның кечкенә өлеше генә...

Илдар ӘХМӘДИЕВ



Юрий ДЕНИСОВ




– Исеңдә тот, Кащей, мафия – үлемсез ул!

Константин ВАСИЛЬЕВ



– Кайсыбыз өстенрәк була инде, димәк?

Айдар ҮТӘГӘНОВ



Вадим МАЛЯКИН



– Тәнәфес вакытында белеп кил әле: бу караватны алар кайдан тапканнар икән?



– Өемне сүтеп атарга җыенасызмы? Алмашка мин дүрт бүлмәледән кимгә риза түгел!

Борис СТАРЧИКОВ



ЯЛ ИТӘРЛЕК УРЫН ЮК...

Кадерле "Чаян"! Җәен рәсәйлеләрнең яраткан ял урыны булып диван саналган. Танзания белән Крымнашка кесә тарырак шул, бөтен кеше дә бара алмый. Безгә бәхет елмайды тагын үзе, безнең диваннан кала, искиткеч Архиерейск күлебез бар. Әлеге күлдә халык коенып, кызынып кына калмый, бик күп бәйрәмнәрне дә үткәрәләр. Тик менә сакланыла торган табигать почмагы булуга карамастан, шаугөр килеп йортлар төзеп яталар. Саклау дигәне дә гади халыктан саклауларыдыр инде. Коттеджларны биек коймалар белән тотып, күл янына бара торган түгел. Ярый әле күлнең бер почмагы гади халык өчен калды. Дәүләт вәкилләре әйтүенә караганда, бернечә урынны сатмый калганнар икән, халык йөрсен дип. Кем белә, вәкилләр алышына тора бит, приказлар яңартыла... халык та ял итү урыныннан колак кагырга мөмкин әле.

ТАРЛАШ авылы халкы

ЛАЕШ районы

ЯШӘҮ ӨЧЕН КӨРӘШ

Хөрмәтле редакция! Безнең бистәдә халык белән иясез этләр арасында чынчынлап көрәш башланды. Дүрт аяклы террорчылардан халык беренче ел гына иза чикми инде. Соңгы вакытларда урам этләре тәмам азынды. 20–30 эттән торган көтүлекләр халык өчен кирәкле урыннарны басып ала башлады. "Находка" кибете мәйданын, 2 нче санлы мәктәп мәйданын, ташландык йорт урыннарын, хәтта кайбер бакчачылык мәйданына да хуҗа булды алар. Бирешмәскә тырышсалар да, киеме умырылмаган, эт тешләмәгән бер көне дә юк бистәдә яшәүчеләрнең. Администрациядән килгән җавап та бик төрле: махсус белгеч кирәк, әлеге проблема 4 нче кварталда гына хәл ителә ала яисә иясез хайваннарга тиешле акча ресурсы ел башында ук тотылган... Гади халыкның сабырлыгы гына җитсен инде, Ходаем!..

Л. ГАЙНУЛЛИНА


ВАСИЛЬЕВО бистәсе,
ЯШЕЛ ҮЗӘН

Хөрмәтле укучыларыбыз!

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Язылган өчен мотоблок һәм башка бүләкләр» акциясе кысаларында бүләкләр уйнату уздырылды. 1079 катнашучы арасында 15 бүләк уйнатылды. Аның нәтиҗәләрен tatmedia.ru/promotions сайты битендә белергә мөмкин.

«Чаян» укучылары белән уйнарга ярата. Шуңа күрә без башкалар белән беррәттән, безнең журналны сайлаганнар арасында өстәмә уйнату оештырдык. Бу юлы бәхет Арча районыннан Рәмзия Габдрахмановага елмайды. Җиңүчене котлыйбыз!







...

Сезнең борыныгыз зур, колакларыгыз тырпайган, күзләрегез кылыймы? Телегез сакау һәм ике аякка да аксыйсызмы? Сезне кызлар яратмыймы? Кирәкми дә! Чөнки нәкъ менә алар аркылы СПИД йога да инде!



Мәгъсүм Хуҗинның тууына – 90 ел



Үзе ачык күңелле булгангадырмы, аның бүлмә ишеге һәрвакыт ачык тора иде. Шуңа күрә "Чаян"га килүчеләр беренче итеп журналның җаваплы секретаре Мәгъсүм абыйның ачык йөзен күрәләр иде. Безнең, ул чакта яшь чаянчыларның, иҗади тормышы да Мәгъсүм абый елмаюыннан һәм аның халыкчан шаяртуларыннан башланды. Егерме ел буе журналда үз вазыйфаларын башкару өстенә, ул гомере буе иҗат белән шөгыльләнде. Мәгъсүм Хуҗин – дистәдән артык китап авторы, Ф. Хөсни исемендәге әдәби бүләк иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Язучылар берлеге әгъзасы.

Мәгъсүм абыйның тууына 90 ел тулу уңаеннан, аны искә алып, укучыларга аның бер хикәясен тәкъдим итәбез.



Әллә ни арада яныбызга күрше-тирә балалары җыелды, алар тыкрык ерганагы комында уйный да башладылар. Күрше Зилә безнең янга йөгереп килде дә:

– Сез нигә уйнамыйсыз? – диде, Мохтарны һәм мине җитәкләп, уенчылар каршына китереп тә бастырды.

Без комнан биек итеп тау өйдек, аның итәгенә тирән итеп елга ердык. Йомычка өйләр буена чыбыклар кададык...

Ком тавында үзебезнең авылны ясап бетергәч, Зилә безне рәтләргә тезде, мин Мохтар белән парлап бастым.

– Мин хәзер сезнең әниегез булам, – диде Зилә. – Сез минем сүзне тыңлагыз, ярыймы? Әниләр сүзен тыңлыйлар. Хәзер клуб бакчасына барып уйныйбыз.

Без анда такта таудан шудык, бүкән өстендәге тактага утырып атындык. Башы җиргә күмелгән үрә баскычның бер ягыннан менеп, икенче ягыннан төшүдә ярыштык. Мин, Зилә-әни унбишкә кадәр санаганда, баскычтан кулларымны ычкындырдым, Мохтар мине узды – унике дигәндә өлгерде.

– Икенче уен башлыйбыз, – диде яңа әниебез. – Халит улым, син эзләүче булырсың.

Ул таш өстенә куелган такта башына уйнаучылар санынча чыбыклар өйде һәм, тактаның икенче башына тибеп, чыбыкларны чәчте. Мин шуларны тиз генә җыярга һәм, качучыларның берсен табып, аңардан алда тактага тибәргә тиеш идем. Аннары табылган кеше эзләүче булып кала.

Мин чыбыкларны җыеп бетергәндә, Мохтар мышкылдык кына качып өлгерә алмаган иде.

– Әнә, әнә Мохтар. Әнә, күрдем, күрдем, качма! – дип кычкырдым мин һәм, тактага тибеп, клуб башына таба йөгердем.

Ул арада хат ташучы Хәбибрахман тавышы ишетелде:

– Кайчаннан бирле эзлим бит сезне! Мохтар бабай, Халит бабай, әйдә, пенсиягезне алыгыз әле.

Тыкрык буенда хат ташучының пенсия китерүен көтеп утыра идек без. Ә Зилә-әниебез хат ташучының быел беренче классны укыган кызы иде.

Алмаз ХӘМЗИН

Кызганыч, әмма шулай

Артистлар, артистлар, артистлар... Бер карасаң, сүгеп ыргытырга була, бер карасаң – рәхмәт әйтергә... Эстрадагыларны әйтәм... Нигә, ни өчен?.. Җырлыйлармы? Җырлыйлар. Бии-бии җырлыйлармы? Бии-бии җырлыйлар. Сикереп-сикереп тә куйгалыйлармы? Куйгалыйлар. Тагын ни кирәк сиңа, диярсез... Менә шул, шул... Миңа алай кирәкми. Миңа зәвыклы кирәк, миңа чын татарча кирәк, миңа акырып-бакырып җырлау кирәкми. Миңа күңелне юата торган җыр-моң агылсын сәхнәдән, радиодан, телевизордан. Минем җаным шушы тели, моны мин генә түгел, бөтен татар тели, милләт тели. Юк, халыкка төрле җыр кирәк, дисезме? Миңа да төрле җыр кирәк, ләкин ул мәгънәле сүзләрдән торырга тиеш лә, көе дә уйландырсын, сагышны бассын, яки күңелне җилкендерсен! Бар бит алар, диярсез. Әйе, бар алар. һәм бик күп тә. Әмма аны ишетергә, тыңларга зарыккан бәгырьләр өзлегәләр. Рәхмәт "Тәртип" радиосына. Тагын үз дулкынында суына башлаган йөрәкләргә җылы сулышын өрә-җылыта, назлый-иркәли. Сагындырган ул җыр-моңнар. Кара син аның матур шигъри сүзләрен, баянгармуннарның ипле итеп кенә шул сүзләр белән сөйләшеп барганына хәйраннар калырлык бит! Җырчының җанытәне сихри музыка дөньясына күчкән бит! Баш очындагы калфагында, түбәтәендә, кәчтүмендә миллилек балкып тора, күлмәгенә Ай нурлары төшкән безнең самими осталык, читегендә әйтерсең лә сандугачлар биешә. Онытылып озак карап торсаң, күз тияр төсле. Алар бит безнең кызлар, егетләр! Юклык заманында мәдәниятебезне үрелеп җитеп булмас биеклеккә күтәргән затлар. Шуңа ирешергә кирәк, шуннан туплыйк егәрне, көчне-куәтне һәм, әлбәттә, сәнгатьне! Илһамнар, Әлфияләр тудырган халык бит без!

Шундый алтын-зөбәрҗәтләрне хәзер тәрбияли алабызмы соң? Юктыр, мөгаен... Аның өчен Илһам кебек – балачактан җәберләнеп үсү кирәкме? Әлфия кебек ятим булыпмы? Юк, юк, юк!.. Ходай язмасын! Әмма хакыйкатьне күрми китү мөмкин түгел.

Үзгәрде, җәмгыять, үзгәрде тормыш – ни әйтергә белмәссең, әйбәткәме-начаргамы? Ләкин шунысы ачык: башка дөньяда яшибез, җәмәгать!.. Кешелек сыйфатлары кими бара, кемнәрнеңдер зур уңышка ирешүе дә сөендерми, хыяллар мохтаҗлык белән киселгән, максатлар турында уйлаган берәр адәм бар микән? Күзләрдән нур качкан, җаннардан иман, киләчәк күренеп торган офыкка кадәр генә.

Җырларда – "яратам", "сөям"... Ә тормышта – киресе. Шигырьләрдә шул гына, хикәя, повесть, романнарда. Ник бер сокланып заман героен укыйм? Юк бит, юк ул. Элек "әллә кем" булып йөргән иҗатчылар "халык шагыйре", "халык язучысы", "халык артисты" булып беттеләр. Инде берничә мәртәбә басылып чыккан әсәрләрен яңа тышлыкка түшәп, калын-калын китаплар чыгардылар. Матбугатта ник бер хикәясе басылсын. Язмыйлар. Беттеләр. Халык белән аралашмыйлар, дөнья хәлен белмиләр. Акчалары бар, хөкүмәт биреп тора. Хәзер аларга язмау, ягъни "эндәшмәү" – алтын. Бар бит шундый мәкаль. Менә тагын берсен әйтеп үтим: "Мәче симерсә, тычкан тотмый" дигәне. Болар да шулай булды, ахрысы.

Артистлар, дип яза башлаган идем бит. Ә болары "мөгҗизә" инде. Ни җырлаганнарын үзләре дә белмиләр. Алдарак әйтеп киткәнемчә, мәхәббәт – аларның репертуарында. Йә – "әни", бала тапса – "бәби" турында. Җырның сүзләре хакында сүз куертасым килми – берниндн тәрбияви, әхлак, намус, вөҗдан мәсьәләсе кузгатылмый. Яшәешебез турында да уйлашулар, җыр белән кеше күңелендә оптимизм уятулар да чагылмый анда. Яңа җырларны кочаклап ыргыталар алар экранга һәм эфирга. Ә халык гөрләп кул чаба. Уйлыйлардыр: "Шушылайдыр инде хәзер, без артта калганбыздыр, менә бит ничек шәп сикерә, менә бит хатыны белән җырлый... Ай колагым, уф йөрәгем, Алла, Алла, башым!.."

Менә шулай итеп, шундый җырлар белән зур бер залда концерт куялар да, түрәләрне чакырып, икенче көнне зур сарайда кулын кысып, "Халкыбыз өчен" зур хезмәт күрсәткәнгә дип, "халык артисты" исемен алалар. Бер уйласаң, ярый әле алар бар... Үзләре җыр язалар, үзләре көен, үзләренә үзләре кул чабалар.





САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 9 (1898) сентябрь 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).


Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 2.09.2020 ел.
Тираж – 1945 Заказ А-2219

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Сбербанктан 900 номеры белән башланган смсның жуликлар җибәрмәгәнен ничек белергә?

2. Бухгалтер өстәлендә ничә кәгазь ятарга тиеш?

3. Кешеләрне кем күбрәк интектерә?

4. Уртача яшь нәрсәне аңлата?

5. Нәрсә ул әкиятләр?

6. Ни өчен депутатларга халыклар дуслыгына лаек булуы кыен?

7. Барлык авырулар нервыдан, дөресме шул?

ҖАВАПЛАР

1. Әгәр сине матур итеп акчаңнан мәхрүм итсәләр, бу инде жуликлар эше, тупас эшләсәләр – монысы Сбербанк. 2. Бер тапкыр авызына күпме тутырып йота ала, шуның хәтле. 3. Акушер. 4. Үзеңне көн саен уртача хис иткәндә. 5. Балаларны ипләп кенә телеяңалыклардагы куркыныч хәлләрне карарга әзерләү. 6. Чөнки дусларны сайлап алмыйлар. 7. Әйе, алар нинди дә булса чир барлыгыннан һәм йоктырырга мөмкинлектән нык какшалган.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 8 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«САГЫНАМЫН КАЕННАРНЫ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
М. НӘРИМАНОВ (Сарман),
Р. САФИН (Балык Бистәсе р-ны, Полянка ав.),
Г. ХАННАНОВ (Томск өлкәсе, Бакчар р-ны, Вавиловка ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Балык Бистәсеннән
Равил САФИН!



Герман ОГОРОДНИКОВ




– Ә халык җиң төшереп эшләгәнгә күрә ач!

Светлана ФӘТТАХОВА



Леонид НАСЫРОВ



– Получка көне бүген!
Шуңа бөтерелә инде монда!

Светлана ПРИВИНА



– Ярамый болай! Хәрби кеше – «гражданский брак»та!

Зөфәр ХӘКИМОВ



